# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **23.11.2024 ел**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 23 ноябрендә 10.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының Йомгаклау протоколы төзелде «I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, Петровский Завод авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мостафин торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;
2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Мостафин торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча йортуче хезмәтләренә түләү);
3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Мостафин торак пунктында һәйкәл төзү һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү – материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мостафин торак пункт территориясендә улэн чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммер очен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү);
5. Мостафин торак пунктында ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка кадәр керү юлын төзү - вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча түләү);

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 64 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 36 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 36 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегендә узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән вакытлы хәрби хезмәт узучы, I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда үзара салым кертергә риза:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мостафин торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Мостафин торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча йортуче хезмәтләренә түләү);

3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Мостафин торак пунктында һәйкәл төзү һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү – материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мостафин торак пункт территориясендә улэн чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммер очен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

5. Мостафин торак пунктында ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка кадәр керү юлын төзү - вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча түләү)

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Петровский Завод авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.Р.Нуртдинов